№2, декабрь, 2013 ел

# Бөреләр

*Балалар һәм үсмерләр газетасы*

## Бу санда:

Мәктәп тормышы
Укучылар уңышлары
Сез иң матур кеше икәнсез ...
Илдәниләр бар икән?
Белемнәрне тикшерик
Иҗат
Ял минуты

### *Яңа ел белән, дуслар!*

Декабрь бураннары, кышкы салкыннарда җемелдәгән йолдызлар алып килгән Яңа 2014 нче ел белән котлыйбыз! Бәйрәмегез мөбәрәк, ризык тулы өстәлегез түгәрәк, күңелле, куанычлы булсын. Эшләрегез уң булсын, чәчәк атсын, күңелегездәге мәрхәмәтлелек нуры җаныгызны тагын да ягымлы, матур итсен, ялкынландырып бизәсен. Бусагаларыгыздан караңгылык, салкынлык, хәвеф-хәтәр атлап кермәсен, бәла-каза йөрмәсен.

### *Спорт.*

**Хоккей беренчелеге.**

11 нче декабрь көнне мәктәп хоккей мәйданчыгында хоккей буенча беренчелеккә мәктәп командалары арасында хоккей ярышы булып узды. Ярышта 6, 7, 8 нче сыйныф укучылар командалары катнашты. Киеренке ярыштан соң 8 В , 6А, 7В сыйныф командасы җиңүче булды. 2 нче урында- 8Б, 6Г, 7А нче сыйныф командасы, 3 нче урын – 8Г, 6Б, 7Б нче сыйныф командасы.

Иң яхшы һөҗүмче- Каюмов А.
Иң яхшы капкачы- Галин А.
Иң яхшы сакчы- Снетков А.
Иң оста уенчы- Зарипов Р.

Барыбызга да киләчәктә шушы уңышны югалтмаска теләп калам.

Зарипов Илназ, 7 нче сыйныф.

### Мәктәп тормышы

1. Өлкәннәр көне уңаеннан укучылар һәм укытучылар лаеклы ялдагы укытучыларның һәм техник хезмәткәрләрне бәйрәм белән котладылар, бүләкләр тапшырдылар.
2. Мәктәп күләмендә үткәреләчәк олимпиадаларга старт бирелде.
3. Мәктәп тәрәзәләре кышны чыгу өчен әзерләнде.
4. Гыйнвар аенда мәктәбебездә фәнни-гамәли конференция булып узды. Бу конфенциядә 54 укучы катнашты.
5. Сыйныф сәгатенә табиблар чакырылды, алар грипп эпидемиясе турында аңлаттылар.
6. 28 нче декабрь көнне мәктәптә Яңа ел бәйрәме үтте."Су патшалыгында кунакта" дигән темага сценарий тәкъдим ителде. Кыш бабай, Карсылу, Су патшасы, Алтын балык, Яңа ел, клоуннар кызыклы тамашада катнаштылар. Укучылар җырлап, биеп күңел ачтылар. Ә Яңа ел бәйрәменә кадәр мәктәп территориясендә кардан шушы ук темага сыннар ясалды.

### *Фән.*

Мәктәптә фән түгәрәкләре эшләп килә. Түгәрәктә укучыларны олимпиадаларга әзерлиләр. Моның нәтиҗәсе яхшы булып, укучылар шәһәр күләмендә үткән олимпиадаларда яхшы урыннар алырлар дип уйлыйбыз.

Шулай ук мәктәптә фән атналыклары да була. Уздырылган мероприятияләр укучыларның белемнәрен тагын да ныгыта.

Бу атна - рус теле атналыгы. Шул уңайдан рус телендә рус әдәбиятының кояшы булган Пушкинга һәм Наталья Гончаровага багышланган кичә үтәчәк. Укучылар чирек ахыры җитүгә, эш күп булуга да карамастан, атналыкка бик теләп әзерләнәләр. Аларга киләчәктә дә тырышып укуларын, актив булуларын теләп калабыз.



### “Ел укытучысы – 2014”

Шәһәребез күләмендә узачак "Ел укытучысы" бәйгесендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы Хәмәтнурова Римма Рим кызы катнашырга теләк белдерде. Без аңа уңышлар теләп калабыз.



## Укучылар уңышлары

## Сез иң матур кеше икәнсез...



Минем апам Фәтхетдинова Зилия алтынчы мәктәпнең 11 Б сыйныфында укый. Без апам белән икәүләп музыка мәктәбенең җыр түгәрәгенә йөрдек. Ул укуда да алдынгы, әнинең беренче ярдәмчесе, кул эшләренә дә оста. Минем апам татар теле һәм әдәбият дәресләрен бик ярата. Бу фән буенча уңышлары бик күп. Аның уңышлары булып шәһәр күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда гел призлы урыннар яулау.

2012-2013 ел - Шәһәр һәм республика күләмендә татар теле һәм әдәбият фәне буенча үткәрелгән олимпиадаларда Почет грамотасы белән бүләкләнде. (җитәкчесе Зарафутдинова Э.Т.)

2013-2014 ел - Шәһәр һәм республика күләмендә татар теле һәм әдәбият фәне буенча үткәрелгән олимпиадаларда Почет грамотасы белән бүләкләнде. (җитәкчесе Зарафутдинова Э.Т.)

Апамны бик яратам һәм аның белән горурланам.

Айгөл Фәтхетдинова, 4 А сыйныф укучысы.

### Минем горурлыгым.

5 нче октябрь көнне ничектер күңел канатланып китте. Нидән бу? Әйе, ник канатланмасын, бүген бит безнең укытучыларыбызның профессиональ бәйрәме. Чәчәк бәйләме күтәреп, укытучыларны бәйрәм белән котлыйсы килде бу көнне.

Укытучы хезмәте - миңа бик таныш. Чөнки, әнием- Әхмәтшина Гөлнара Фәнил кызы 18 ел Нефтекама шәһәренең № 6 мәктәбендә укытучы булып эшли. Ул- ачык йөзле, итагатьле, сабыр, һәр балага ярдәм кулы сузарга әзер тора.

Хезмәтен җиңел дип әйтмәс идем. Һәр көн сумка тутырып китап, дәфтәр күтәреп кайтуы, аны укучы бала дәрес хәзерләгән кебек, сәгать 12 ләргә кадәр укып, тикшереп утыруы моңа мисал.

Әниемнең октярь аенда икеләтә бәйрәме. Беренчесе- укытучылар көне булса, икенчесе- 14 октябрь көнне туган көне. Мин аны бу бәйрәмнәре белән чын күңелемнән котлыйм. Тормышында бәхет, шатлык, тынычлык, эшендә зурдан-зур уңышлар телим. Күләч йөзеңнән гел елмаю китмәсен, шат бул әнием!

Әхмәтшин Марат, 8 нче сыйныф.



### Беренче укытучым!

Иң авыры, минемчә, яраткан укытучың турында язу. Җанны тутырган ярату һәм соклану хисләрен ничек ак кәгазьгә төшерергә? Кәгазьгә күчкәндә аларның ихласлылыгы да, көче дә югала сыман.

Укытучы, мәктәп! Бу ике сүз.<br>
Күңелемдә яши янәшә.<br>
“Мәктәбем!”- дип дәшкән чакта күңел,<br>
“Укытучы”- дип йөрәк эндәшә.

Укытучы! Әлеге сүзне ишетүгә күбебезнең күз алдына нәни кулыбыздан тотып язарга өйрәткән беренче укытучыбыз килеп баса. Ничек кенә булмасын, һәр кешенең “Менә ул чын укытучы”, – диярлек остазы бар. Ул аны еллар узган саен сагынып искә ала, гомере буена рәхмәт укый.

Минем онытылмас укытучым – Гатауллина Гөлназ Филюс кызы. Инде бик күп еллар балаларга белем бирә. Шул еллар дәвамында ул бик күп балаларны хәреф танырга, укырга өйрәтте.

1 нче сентябрь беренче сыйныфка укырга кергән 25 бөртек балада мәктәпкә мәхәббәт уятты. Олыны – олы, кечене – кече итәргә, ярыша – ярыша бер – беребездән уздырып, тырышып укырга өйрәтте Гөлназ Филюс кызы.

Укытучы апабызның ачуланганын, тавыш күтәреп кычкырганын бер дә хәтерләмим. Безне өйдә үз дигәнен генә эшләп өйргән 25 тиктормасны ничек тыңлаткандыр, белмим. Гел елмаеп кына торучы укытучыбызны үзебез дә бик ярата идек шул. Без өлкән класста укысак та, аның янына хәзер дә йөгерәбез.

Укытучы апа миңа<br>
Әни кебек кадерле<br>
Аның йөзе нур сибүче,<br>
Кояш кебек сөйкемле.<br>
Сезнең өчен матур сүзләр<br>
Бик тә, бик тә аз булыр.<br>
Аерылгач сезне уйлап<br>
Һәрчак күңлебез тулыр.

Мин хәзер 6 нчы сыйныфта укыйм. Шулай да Гөлназ Филюс кызы гел искә төшеп сагындыра. Аның белән сөйләшәсе, серләшәсе килгән чаклар да була. Гөлназ Филюс кызы, мәңге шундый яшь, шундый матур булып калыгыз. Беркайчан да картаймагыз.

Әлзәмова Алия, 6 Б нчы сыйныф укучысы .

# Илдә ниләр бар икән?

## Олимпиада уты Уфа аша үтте

Һәр шәһәр бу эстафетага үзенчә бер яңалык өсти. Башкортстан аны, Русиягә үрнәк булырдай каршы алып, югары дәрәҗәдә оештырды.
Олимпиада уты килеп җиткән көнне Башкортстанны салкыннар уратып алды: бу факелны йөртүчеләр өчен генә түгел, бөтен республика өчен дә сынауга әверелде.
Чараны оештыручылар факел йөртүхеләрнең суыкка түземле булуын шифалы башкорт балының сихәте белән бәйләделәр.
Уфа вокзалында Олимпиада утын каршы алганнан соң аны беренче булып Олимпиада-2004 уеннарында бронза медаль яулап кайткан Руслан Насыйбуллин урам буйлап күтәреп алып китте. Аңардан соң факелны спорт яратучы 15 яшьлек Данил Аиткулов алды, өченче факел йөртүче исеменә – республикада һәм Русиядә күренекле футбол судьясы, М. Акмулла исемендәге БДПУ тәмамлаучы, бүгенге көндә “Уфа” футбол клубының спорт директоры Илдус Биглов лаек булды. Факелны шәһәрнең үзәк – Карл Маркс, Пушкин, Тукай, Зәки Вәлиди, Совет, Сочи урамнары буйлап, аннан С. Перовская, Аврора, Рабкоров, С.Кувыкин, Менделеев урамнары буйлап дәвам иттеләр, Салават Юлаев исемендәге мәйдан, Дуслык монументы, “Олимпик парк”, “Акбузат” ипподромыннан да үттеләр. Үсмерләр арасында пятиборье буенча Европа чемпионкасы исемен яулаган Гөлназ Гобәйдуллина факелны атка атланып йөртте. Заман пятиборьесы буенча күп тапкыр дөнья чемпионы Рөстәм Сабирхуҗин да үз дистанциясен атка атланып үтте. Аларны 800 Кыш бабай сәламләде. Олимпиада уты үзенең эстафетасын дәвам итә: Башкортстаннан аны Ырынбур өлкәсе кабул итте. Эстафета 7 февральдә Сочида тәмаланачак. Шушы көнгә кадәр ул илнең 2900 торак пунктында булып, 65 мең чакрым юл үтәчәк. Җиңел автомобильдә, самолетта, поездда, боланнарда һәм вертолетта үтеп, 14 мең факел йөртүченең кулында булачак.






## Уфа аквапарклы булды

Әлеге тантанада БР Президенты Рөстәм Хәмитов та катнашты. “Уфа һәм Башкортстанда яшәүчеләрнең күптәнге хыялы тормышка ашты. Без мондый аквапаркның барлыкка килүен еллар буе көттек. Хәзер аквапарк дип Магнитогорск шәһәрләренә барудан туктарбыз инде. Әлбәттә, бу эш җиңел бирелмәде. Мондый бинаны төзүе бик авыр, мин әлеге проект өстендә эшләгән төзүчеләргә һәм дизайнерларга рәхмәт сүзләре әйтәм”, – диде Рөстәм Хәмитов. Аквапаркның гомум мәйданы 5 мең 400 квадрат метр тәшкил итә, хәвефсезлекне сертификацияләре булган 100 инструктор тәэмин итәчәк. Бассейн динозаврлар белән тропик күле кебек ясалган, әчтә берничә су таулары бар- “Су әйләнмәсе” (ябылган торба буйлап шуу, азагында зур әйләнмәгә һәм бассейнга эләгү), “Тиз елга”, “Тау елгасы”, “Анаконда”. Шулай ук кыюлар өчен экстремаль таулар да каралган: “Ирекле төшү”, “Камикадзе”. Олы яшьтәгеләр өчен аерым зона булдырылган, анда сауна һәм төрекчә мунча ясалган. Аквапаркта шулай ук алты кафе һәм ресторан бар. Эш көннәрендә олылар өчен тулы бер көнгә билет хакы 1300 сум тәшкил итәчәк, 5тән 12 яшькә габалалар өчен 900 сум. (Бәйрәм көннәрендә керү 500 сумга кыйммәтләнәчәк). 4 сәгатькә билет хакы – 1000 сум, балалар өчен – 700 сум, бәйрәм көннәрендә – 1400 һәм 900 сум. Дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә профилактик эшләр башкарылачак. Сишәмбе һәм чәршәмбе көнне аквапарк 10:00-22:00га кадәр, җомга һәм шимбә – 10:00-24:00га кадәр, якшәмбе көнне 23:00га кадәр эшләячәк.

## Белемнәрне тикшерик

# Габдулла Тукай тормышы һәм иҗаты буенча тест








*1. Габдулла Тукайның туган авылы:*
а) Кушлавыч   ә) Кырлай   б) Сасна   в) Өчиле

*2. Габдулла Тукайның әнисенең исеме:*
а) Сажидә   ә) Газизә   б) Мәмдүдә   в) Зөһрә

*3. Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф кайсы авылда мулла була?*
а) Кушлавыч   ә) Сасна   б) Кырлай   в) Өчиле

4. Габдулла Тукайның әнисе кайсы авылда вафат була?
а) Кушлавыч   ә) Сасна   б) Кырлай   в) Өчиле

*5. Әнисе икенче авыл кешесенә кияүгә чыгып киткәч, кечкенә Тукай вакытлыча кем кулында калып тора?*
а) Сабира   ә) Сажидә   б) Газизә   в) Шәрифә

*6. Габдулла Тукай үзенең «Шүрәле» әсәрендә кайсы авыл табигатен тасвирлый?*
а) Кушлавыч   ә) Сасна   б) Кырлай   в) Өчиле

*7. Кырлай авылында ул кем гаиләсендә яши?*
а) Мөхәммәтгалим   ә) Сәгъди
б) Мөхәммәтвәли
в) Фәтхерахман

8. *Казанда Габдулла Тукайның әти-әнисе кемнәр була?*
а) Мөхәммәгали-Мәмдүдә
ә) Мөхәммәтвәли-Газизә
б) Сәгъди-Зөһрә
в) Галимҗан-Газизә.

*9. Габдулла Тукай ничәнче елда вафат була?*
а) 1899   б) 1913
ә) 1887   в) 1907

# Иҗат

## Яңа ел белән!



Энҗеләрдәй мамык карлар ява,
Җир йөзенә Яңа ел килә.
Өметләнәм - алып килер бу ел
Тынычлык һәм иминлек илгә!

Еллар хушлашканда-очрашканда
Тыныч калыр кеше бар микән?
Офыкларны иңләп җиргә яуган
Бәхет микән, әллә кар микән?

Хуш киләсең, әйдүк, яңа елым,
Урының синең илем түрендә.
Җиңел аяк белән кил син безгә,
Ныклап бас син туган җиремә!

Зилия Фәтхетдинова, 11 Б сыйныф укучысы.

## Килә елның яңасы

Бар тирә як балкып тора,
Җирем актан киенгән.
Әйтерсең дә, сихри күктән
Көмеш тәңкә сибелгән!

Яңа елның ак карлары
Илгә муллык китерсен,
Яңа елда һәрбер кеше
Куанычлар кичерсен!

Алсу Гомәрова, 7 Б сыйныф укучысы.



## Хыяллар чынга ашсын

Кыш – минем яраткан ел мизгеле. Әле кайчан гына кара булып яткан җир мамыктай ак кар белән капланды. Бөтен дөньяда аклык, сафлык. Кышкы табигать бигрәк матур. Ак каеннар, ябалдашлы наратлар, киң итәкле чыршылар ак тун кигәннәр. Аларга аз гына кагылсаң, ботакларындагы, кәүсәлә-рендәге бөтен аклык өстеңә ишелер шикелле. Иртән мәктәпкә барганда, яңа яуган ак карга эз салып баруы – үзе бер могҗиза! Кар өстендәге эзләр күп нәрсә турында сөйли. Әнә кемнеңдер өенә кереп киткән ул эз. Каршы яктан чаналы ат узган. Юл читендә этләр уйнаган... Мондый матурлыкны кыш көне генә күзәтергә мөмкин.


Кышкы уеннары гына да ни тора бит! Рәхәтләнеп чаңгыда, чанада, тимераякта шуасың, кар йомарлап атышасың. Кышны мин Яңа ел алып килүче мизгел булган өчен дә көтеп алам. Ул минем иң яраткан бәйрәмнәремнең берсе. 7 сыйныфта укысам да, һаман Кыш бабайның могҗизаларына ышанам. Мин ел да аңардан берәр нәрсә сорыйм. Теләкләремнең иң зурысы – һәрвакыт тынычлык булсын. Мин укыган мәктәпнең ишекләре балалар өчен һәрвакыт ачык булсын, чөнки ел да безнең авылда мәктәпне ябабыз дип куркыталар. Минем өчен туган авылымдагы туган мәктәбемдә укудан да зур бәхет юк. Кыш бабай минем теләгемне ишетер һәм ярдәм итәр дип ышанам.

Марсель Миңнуллин, 7 В сыйныф укучысы.



# Ял минуты

## Аерма тап





## В хәрефенә ребуслар

Рәсемнәрдә нәрсәләр сурәтләнгән? Һәр сүзнең беренче хәрефен алып, ребуста нинди сүз яшерелгәнен тап.

**В**  **Т А Н**

Нинди сүзләр килеп чыкты?

Безнең адрес: Нефтекама шәһәре, Социалистик урамы, 45 Б санлы йорт.
Белешмәләр өчен телефон: 8(927) 322-53-73.